СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

№2-24 от 20 июнь 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Никифорово авыл
җирлеге муниципаль милкенә карата
концессион килешү төзү турында
карар кабул итүгә ризалык бирү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Никифорово авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Никифорово авыл җирлеге башкарма комитетына коммуналь инфраструктура һәм башка коммуналь хуҗалык объектларына, шул исәптән су белән тәэмин итү объектларына, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системаларына, мондый системаларның аерым объектларына хезмәт күрсәтүгә концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирергә.

2. 1 нче кушымтада бирелгән күчемсез мөлкәтне концессион килешү объектлары итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән (басылып чыккан) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районыны Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н.Степановка йөкләргә.

Никифорово авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /С.Н.Степанов/

1 нче кушымта

Концессион килешү объектлары, шул исәптән техник-икътисадый күрсәткечләре, техник халәте, хезмәт срогы

| № п/п | объектның исеме | Кадастр номеры | урнашу урыны адресы ( торак пункт/ур.) | Техник параметрлар (мәйдан/диаметр/биеклек/озынлыгы һ.б.) | Гамәлгә керү елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Суэтем башнясы Никифорово авылы | 16:26:480101:776 | РФ, Татарстан Республикасы , Мамадыш районы, Никифорово авылы | Суэтем башнясы Н-12 м , тирәнлек 100 м. металдан | 1979 |
| 2 | су үткәргеч челтәре Никифорово авылы | 16:26:000000:4440 | РФ, Татарстан Республикасы , Мамадыш районы, Никифорово авылы | су үткәргеч челтәре озынлыгы 3977м. п/э D - 110 | 1979 |
| 3 | Суэтем башнясы Сәртек авылы | 16:26:480101:774 | РФ, Татарстан Республикасы , Мамадыш районы, Сәртек авылы | Суэтем башнясы Н-12 м , гтирәнлек 100 м. металдан | 1979 |
| 4 | су үткәргеч челтәре Сәртек авылы | 16:26:000000:4396 | РФ, Татарстан Республикасы , Мамадыш районы, Сәртек авылы | су үткәргеч челтәре озынлыгы 3304м. п/э D - 110 | 1979 |

Никифорово авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /С.Н.Степанов/

СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НИКИФОРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИНН 1626001362